**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

# АЛАР ИЛГӘ ҖИҢҮ АЛЫП КАЙТТЫ

# ОНИ ВЕРНУЛИСЬ С ПОБЕДОЙ

## Саба районы

## Сабинский район

**КАЗАН**
**КАЗАНЬ**
**2018**

УДК 331
ББК 65.9 (2) -6
О 58

**Редакционная коллегия:**

**А.А. САФАРОВ —** Руководитель Аппарата Президента Республики Татарстан, председатель редакционной коллегии
**Р.М. ВАЛЕЕВ —** главный редактор Государственного бюджетного учреждения Республики Татарстан «Редакция «Книга Памяти»
**Б.К. КУЗНЕЦОВ —** Герой Советского Союза
**Г.Р. НАЗИПОВА —** генеральный директор Национального музея Республики Татарстан
**А.Ш. САДРИЕВ —** директор музея лицея № 9 г.Зеленодольск
**Р.Р. САЛАХИЕВ —** заведующий научно-издательским отделом Института Татарской энциклопедии АН Республики Татарстан
**И.Р. ТАГИРОВ —** академик АН Республики Татарстан
**Р.С. ХАКИМОВ —** директор Института истории АН Республики Татарстан
**М.В. ЧЕРЕПАНОВ —** заведующий Музеем-мемориалом Великой Отечественной войны в Казанском кремле
**А.Г. ЮЛАШЕВ —** председатель Комитета ветеранов войны и военной службы Республики Татарстан

**Они вернулись с Победой.** Сабинский район. – Казань: «Книга Памяти», 2018. – 384 с.

**ISBN 978-5-900018-44-7**

Книга издается по Постановлению Кабинета Министров Республики Татарстан
от 3.12.2003 г., № 623.
Китап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 3.12.2003 кабул ителгән
623 номерлы Карары нигезендә нәшер ителә.

Эта книга – знак благодарности сынам и дочерям Татарстана – тем, кто родился, жил или призван в Республике Татарстан, сражался на фронтах Второй мировой войны и вернулся с Победой. На страницах этого тома собраны сведения о 3216 воинах, уроженцах и жителях Сабинского района.

Редакция выражает благодарность администрации Сабинского района, всем, кто помогал составлению этого тома – сотрудникам военкомата, ЗАГСа, органов местного самоуправления, архивов, а также ветеранским, поисковым и другим общественным организациям. Особая благодарность сотрудникам Сабинского краеведческого музея за координацию работы по сбору и сверке списков.

Бу китап – Икенче бөтендөнья сугышы кырларыннан Җиңү яулап кайткан Татарстан уллары һәм кызларына рәхмәт билгесе. Бу томга Саба районында туган һәм яшәгән 3216 сугышчы турында мәгълүмат тупланган.

Редакция әлеге томны әзерләүдә булышлык күрсәткән Саба районы хакимиятенә, район хәрби комиссариаты, ЗАГС, җирле үзидарә, архив хезмәткәрләренә, шулай ук ветераннар, эзләнүчеләр һәм башка җәмәгать оешмаларына рәхмәт белдерә. Исемлекне төзү һәм тикшерү эшен оештырган Саба туган төбәк тарихы музее хезмәткәрләренә аерым рәхмәтен җиткерә.

**ISBN 978-5-900018-44-7**

© Государственное бюджетное учреждение Республики Татарстан
«Редакция «Книга Памяти», 2018

# СЛОВО К ЧИТАТЕЛЮ

Память...

Святое человеческое чувство. Она живет в нашем сознании вечно. И не просто живет, а зовет все новые и новые поколения людей на подвиги, равняя дела сегодняшние на свершения героев прошлого.

Никогда не изгладятся в памяти человечества 1418 дней и ночей Великой Отечественной войны Советского Союза с фашистским нашествием.

Имена всех, кто остался на полях сражений, увековечены в Книгах Памяти. Книга Памяти Республики Татарстан вместила около 350 тысяч имен наших земляков, не вернувшихся с войны. Это особый памятник нашим отцам, дедам и прадедам.

На долю фронтовиков, которым удалось вернуться с войны живыми, досталось самое трудное – поднимать страну из разрухи. Не снимая шинелей, они приступили к восстановлению народного хозяйства. Судьбы этих людей – яркое свидетельство служения Отечеству, пример для подражания молодому поколению. Настало время назвать их поименно.

В книге, которую вы держите в руках, публикуются списки уроженцев и жителей Республики Татарстан, мобилизованных военными комиссариатами ТАССР, сражавшихся на фронтах Второй мировой войны и вернувшихся с Победой.

В списки вошли участники не только Великой Отечественной войны (1941-1945), но и Советско-финляндской войны (1939-1940), других военных конфликтов (1939-1945). Они составлены в первую очередь на основании книг призыва районных военкоматов республики путем исключения тех солдат и офицеров, на которых пришли сведения о гибели или пропаже без вести.

Краткие сведения об участниках войны собраны в архивах районных военкоматов, Национальном архиве РТ, Центральном государственном архиве историко-политической документации РТ, архиве управления Федеральной службы безопасности РФ по РТ (КГБ), Министерства внутренних дел по РТ, архивах предприятий и организаций, музеев и поисковых организаций РТ, на сайтах Министерства обороны РФ «Подвиг народа» (www.podvignaroda.ru),

# УКУЧЫГА

Хәтер...

Бары тик кешеләргә генә хас изге хис. Ул безнең аңда мәңге яши. Яшәп кенә калмый, ә яңадан-яңа буын кешеләрен батырлыкларга өнди, хәзерге гамәлләрне элекке каһарманлыкларга тиңләргә чакыра.

Бөек Ватан сугышының канкойгыч 1418 көне һәм төне кешелек хәтерендә мәңге сакланыр.

Яу кырында ятып калганнарның исемнәре Хәтер Китабы битләрендә мәңгеләштерелде. Татарстан Республикасының Хәтер Китабында сугыштан кайтмаган 350 мең якташыбыз турында мәгълүмат тупланган. Бу безнең ата-бабаларыбызга аерым бер һәйкәл.

Сугыштан әйләнеп кайткан фронтовиклар каршына илне торгызу бурычы басты. Шинельләрен дә салмыйча, алар халык хуҗалыгын аякка бастыруга керештеләр. Әлеге кешеләр язмышы – яшь буын өчен Ватанга хезмәт итүнең калку үрнәге. Инде аларның һәрберсен аерым атап, аерым исемләргә вакыт җитте.

Сезнең кулыгыздагы бу китапта Татарстанда туган, яшәгән, ТАССР хәрби комиссариатлары тарафыннан мобилизацияләнгән, Икенче бөтендөнья сугышы фронтларын кичеп, илгә Җиңү алып кайткан якташларыбыз исемлеге китерелә.

Исемлеккә Бөек Ватан сугышында (1941-1945) гына түгел, Совет-фин сугышында (1939-1940), башка хәрби конфликтларда (1939-1945) катнашучылар да кертелде. Алар нигездә район хәрби комиссариатларында саклanган чакырылыш китапларыннан һәлак булу яки югалу турында хәбәре килгән солдат-офицерларны төшереп калдыру юлы белән төзелде.

Сугышта катнашучылар турында кыскача белешмәләр район хәрби комиссариатлары архивларында, ТР Милли архивында, ТР Үзәк дәүләт тарихи-сәяси документлар архивында, РФ Федераль иминлек хезмәтенең ТР буенча идарәсе (КГБ), ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы архивларында, предприятие һәм оешмалар, ТР музейлары һәм эзләнү оешмалары архивларында, җирле үзидарә органнарында тупланды, шулай ук

«Память народа» (www.pamyat-naroda.ru), а также предоставлены органами местного самоуправления.

Мы отдаем себе отчет в том, что собрать полные сведения о каждом участнике войны, мобилизованном или жившем на территории того или иного района, практически невозможно. Даже если человек выжил на фронте, он мог не вернуться после войны домой по разным причинам. И узнать о его послевоенной судьбе порой практически не представляется возможным: не сохранились не только документы, но и сами населенные пункты, нет в живых многих членов семей, провожавших солдата в армию.

Немало примеров, когда ветеран прибывал в республику в послевоенные годы и оставил заметный след в истории, трудовых свершениях Татарстана, того или иного района или города. Не назвать его в списке победителей, тех, кто восстанавливал страну после войны, было бы несправедливо.

Учитывая все это, редакционная коллегия сочла необходимым включить в книгу все имеющиеся сведения о каждом фронтовике, мобилизованном или жившем после войны на территории Республики Татарстан.

Текст дан на русском и татарском языках. Данные о каждом унифицированы и располагаются в следующей последовательности: **фамилия, имя, отчество; год рождения; место рождения; место жительства; дата мобилизации, воинское звание и должность, место службы, дата демобилизации; место работы, должность (после войны); ордена и почетные звания; дата смерти и место захоронения.**

В скобках даются варианты фамилий и имен, года рождений, встречающиеся в разных документах об одном и том же человеке.

Решением Кабинета Министров РТ подготовка и утверждение списков для книги «Они вернулись с Победой» была возложена на специально созданные комиссии при администрациях районов и городов республики. **Они и предоставили окончательный вариант списков в редакцию.**

Ваши дополнения и замечания присылайте по адресу:

**420015, г.Казань, ул. Тельмана, д. 5,**
**редакция «Книга Памяти».**

РФ Оборона министрлыгының «Подвиг народа» (www.podvignaroda.ru) һәм «Память народа» (www.pamyat-naroda.ru) сайтларыннан алынды.

Район территориясендә яшәгән яисә шуннан мобилизацияләнгән һәрбер сугышта катнашучы турында мәгълүматны тулысынча җыю мөмкин түгеллеген без аңлыйбыз. Фронтта исән калса да, сугышчы төрле сәбәпләр нигезендә туган җиренә әйләнеп кайтмый калган булырга мөмкин, һәм аның сугыштан соңгы язмышын ачыклау мөмкинчелеге бик чикле: ул вакыттагы документлар гына түгел, торак пунктлар да сакланмаган, солдатны армиягә озаткан гаилә әгъзаларының күбесе инде вафат.

Республикабызга сугыштан соң килеп, Татарстанның, теге яки бу район, шәһәрнең тарихында тирән эз калдырган, зур хезмәт казанышларына ирешкән ветераннар да күп. Аларны сугыштан соң илне аякка бастырган җиңүчеләр исемлегенә кертми калдыру берничек тә дөрес булмас иде.

Алда әйтелгәннәрне искә алып, редакция коллегиясе китапка Татарстаннан мобилизацияләнгән яки республика территориясендә сугыштан соң яшәгән һәрбер фронтовик турында булган барлык мәгълүматны кертү кирәк дип тапты.

Текст рус һәм татар телләрендә бирелә. Кыскача белешмәләр түбәндәге тәртиптә китерелә: **сугышчының фамилиясе, исеме, атасының исеме; туган елы; туган урыны; яшәгән урыны; мобилизацияләнү елы, хәрби дәрәҗәсе һәм сугышчан вазифасы, хезмәт урыны (рус телендә генә китерелә); демобилизацияләнү елы; сугыштан соңгы эш урыны һәм шөгыле; орденнары һәм мактаулы исемнәре; вафат булган вакыты һәм җирләнгән урыны.**

Исем-фамилияләр, туган еллар документларда төрлечә бирелгән очракта, җәя эчендә аларның вариантлары күрсәтелде.

ТР Министрлар Кабинеты карары нигезендә «Алар илгә Җиңү алып кайтты» китабы өчен исемлекләрне төзү эше район һәм шәһәр хакимиятләре каршында махсус оешкан комиссияләргә йөкләнде. **Исемлекнең соңгы варианты алар тарафыннан әзерләнде.**

Киңәш-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адрес буенча кабул итәргә әзербез:

**420015, Казан ш., Тельман ур., 5 йорт,**
**«Хәтер Китабы» редакциясе.**

# ВОЙНА. ПОБЕДА. ПАМЯТЬ

В судьбах народов и государств немало событий, которые изменили мир. Но история не знала более глобального, разрушительного и кровопролитного столкновения, чем война, которую пришлось вести советскому народу против нацистской Германии. 1418 дней и ночей продолжалась яростная схватка с ненавистным врагом, прежде чем четырехлетняя борьба с фашизмом увенчалась Победой. В ожесточенных сражениях с серьезным и хорошо подготовленным противником советские люди показали свои лучшие качества – высокий патриотизм, несгибаемую силу воли, стойкость и самопожертвование.

В эту общую борьбу Сабинский район внес свой весомый вклад. Более 12 тысяч человек ушли на фронт. Невосполнимые потери понесли сабинцы, оставив на полях сражений более 6 тысяч своих лучших сынов и дочерей.

Проходят годы, и редеют ряды ветеранов – тех, кто был живым свидетелем тех тяжелых лет, кто с оружием в руках защищал родную землю, кто своим самоотверженным трудом приближал День Победы в тылу.

За героизм и мужество, проявленные в боях, многие уроженцы Татарстана отмечены государственными наградами. Из Сабинского района 4 человека удостоились высшего воинского отличия – звания Героя Советского Союза.

Хазиев Валий Хазиахметович – рядовой, стрелок. Родился в 1925 г. в с.Уют. После окончания начальной школы работал в колхозе. В 1943 г. был призван в армию, на фронте с июня 1944 г. Валий Хазиев был рядовым бойцом 1126-го полка (334-я стрелковая дивизия, 43-я армия, I Прибалтийский фронт), участвовавшего летом 1944 г. в освобождении Белоруссии. Часть, в которой он служил, порвав сильную, глубоко эшелонированную оборону противника на широком участке, шла к Западной Двине. На другом берегу стоял Витебск.

Взвод Хазиева при переправе входил в состав головного отряда полка. Рядом с командиром он первым ступил на западный берег. Пулеметный огонь задержал перебравшихся через реку бойцов

# СУГЫШ. ҖИҢҮ. ХӘТЕР

Илләр, кешеләр язмышында дөньяны астын өскә китереп үзгәрткән вакыйгалар була. Әмма совет халкы нацистик Германиягә каршы алып барырга мәҗбүр булган канкойгыч, җимергеч, бөтен җир шарын биләп алган героик көрәшнең тарихта тиңе булдымы икән? Дошманга каршы нәфрәт уяткан бу көрәш 1418 көн һәм төн дәвам итә һәм бары дүрт елдан гына Җиңү белән тәмамлана. Җитди һәм яхшы хәзерлекле дошман көчләренә каршы аяусыз сугышта совет халкы матур сыйфатларын – ватанпәрвәрлек хисен, ихтыяр көчен, рух ныклыгын һәм үз-үзен корбан итәргә әзерлеген күрсәтте.

Әлеге уртак көрәшкә Саба районы халкы да үзеннән зур өлеш кертте. Район 12 меңнән артык улкызын фронтка озатты, әмма шуларның 6 меңнән артыгына яу кырыннан әйләнеп кайтырга насыйп булмады.

Еллар эзсез генә узмый. Шул авыр елларның тере шаһитлары булган, кулларына корал алып Ватан сагына баскан, фидакарь хезмәтләре белән тылда Җиңү көнен якынайткан ветераннарыбызның сафы да сирәгәя бара.

Бик күп татарстанлылар сугышта күрсәткән батырлыклары өчен дәүләт бүләкләренә лаек булалар. Саба районының 4 батыр улы иң югары хәрби дәрәҗә – Советлар Союзы Герое исемен ала.

Хаҗиев Вәли Хаҗиәхмәт улы – рядовой, укчы. 1925 елда Оет авылында туа. Башлангыч мәктәпне тәмамлап, колхозда эшли. 1943 елда армиягә алына, 1944 елның июненнән фронтта.

Вәли Хаҗиев 1944 елның җәендә Белоруссияне азат итүдә катнаша, 1126 укчылар полкы (334 укчылар дивизиясе, 43 армия, I Балтыйк буе фронты) сугышчысы була. Ул хезмәт иткән часть, дошманның ныгытылган көчле оборонасының киң өлешен өзеп, Көнбатыш Двинага таба хәрәкәт итә. Елганың икенче ярында – Витебск шәһәре.

Хаҗиев взводы елганы кичкәндә полкның баш отряды составында була. Командир белән янәшә ул, беренчеләрдән булып, көнбатыш ярга аяк баса. Елганы кичкән сугышчыларны яр буенда пулемет уты токтарлый, алар окопларга яшеренергә мәҗбүр

и заставил окопаться. Валий понимал, что сейчас от его решительности зависит жизнь товарищей и удача операции. Не раздумывая долго, он выбрался из своего окопчика и полез к пулемету. Прошли считанные минуты. Одна, вторая граната полетели вперед, и пулемет вместе с расчетом был уничтожен. У деревни Стуканы немцы контратаковали части, идущие в обход Витебска. В этом бою Хазиев застрелил двух гитлеровцев, сам тоже получил ранение. Но он не покинул поле боя, и только когда бой затих и противник отступил, Валий пошел в санчасть. Родина по заслугам оценила подвиг своего храброго сына: 22 июля 1944 г. ему было присвоено звание Героя Советского Союза.

С 1949 г., после демобилизации из армии, жил и работал в Зеленодольске.

Закиров Гали Закирович – младший сержант, командир стрелкового отделения. Родился в 1910 г. в с.Богатые Сабы. В армию был призван в июне 1941 г. Служил в стрелковом отделении 3-го батальона 8-го гвардейского воздушно-десантного полка (3-я гвардейская воздушно-десантная дивизия, 60-я армия, Воронежский фронт).

26 сентября 1943 г. части стрелковой дивизии, где служил Гали Закиров, высадились на западном берегу Днепра и повели борьбу за расширение плацдарма. Несколько дней стрелки при поддержке артиллерии отбивали вражеские контратаки. Постепенно сопротивление немцов слабело и дивизия упорно продвигалась вперед. 5 октября она прорвала оборону противника у деревни Губин. Первым в немецкие траншеи бросились бойцы отделения младшего сержанта Закирова.

Отделение без потерь достигло второй линии обороны противника, выбило с высоты 125,7 немцев. Командир Гали Закиров лично уничтожил более сотни солдат и офицеров врага. О подвиге младшего сержанта Закирова была опубликована заметка в газете «Правда». За отвагу и мастерство ведения боя за высоту 125,7 на берегу Днепра 10 января 1944 г. ему присваивается звание Героя Советского Союза.

Боевые товарищи Гали Закирова не раз восхищались его подвигами в зимнем наступлении 1944 г. на Украине и тяжело переживали гибель сержанта в феврале 1944 г.

Хабибуллин Заки Хабибуллович – подполковник, командир стрелкового полка. Родился в 1911 г. в с.Верхние Отары. В 1931 г. был призван в армию, в 1935 г. окончил военно-политехническое училище, в 1940 г. – курсы политсостава, находился на комсомольской и политтехнической работе

булалар. Вәли шуны аңлый: менә хәзер сугышчан иптәшләренең тормышы һәм операциянең уңышлы тәмамлануы бары тик аның тәвәккәллегеннән тора. Озак уйлап тормастан, яшеренгән урыныннан чыгып, шуышып, пулемет аткан якка юнәлә. Санаулы минутлар уза. Башта беренче, аннан икенче гранатасын ыргыта – пулемет оясын юк итүгә ирешә. Немецлар Стуканы авылы янында Витебск шәһәрен камарга барган совет частьларына контрһөҗүм оештыралар. Бу сугышта Хаҗиев ике гитлерчыны юк итә, үзе дә яралана. Әмма сугыш кырыннан китми, бәрелеш тәмамланып, дошман кире чигенгәч кенә санитария частена юл ала. Ватан кыю улының батырлыгын югары бәяли: 1944 елның 22 июлендә аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

1949 елдан, демобилизацияләнгәч, Яшел Үзән шәһәрендә яши һәм эшли.

Закиров Гали Закир улы – кече сержант, укчылар отделениесе командиры. 1910 елда Байлар Сабасы авылында туа. 1941 елның июнь аенда армия сафларына алына. 8 гвардия һава десанты полкының 3 батальоны (3 гвардия һава десанты дивизиясе, 60 армия, Воронеж фронты) составындагы укчылар отделениесендә хезмәт итә.

Гали Закиров хезмәт иткән дивизия частьлары 1943 елның 26 сентябрендә Днепрның көнбатыш ярына төшеп утыралар һәм плацдармны киңәйтү өчен көрәш алып баралар. Берничә көн укчылар туплар ярдәмендә дошманның контрһөҗүмен кире кайтаралар. Акрынлап немецларның каршы торуы көчсезләнә һәм дивизия алга ыргыла. 5 октябрьдә Губин авылы янында дошман оборонасы өзелә. Немец траншеяларына, беренчеләрдән булып, кече сержант Закиров отделениесе сугышчылары ташлана.

Отделение югалтуларсыз дошман оборонасының икенче линиясенә барып җитә һәм 125,7 биеклеген азат итә. Командир Гали Закиров үзе генә дә ул көнне немецларның йөздән артык солдат һәм офицерын кырып сала. Кече сержант Закировның батырлыгы турында «Правда» газетында мәкалә басыла. Сугыш алып бару осталыгы, Днепр ярларындагы 125,7 биеклеген алганда күрсәткән батырлыгы өчен 1944 елның 10 гыйнварында аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Гали Закировның сугышчан иптәшләре 1944 елда Украинада барган кышкы һөҗүмнәр вакытында да аның батырлыгына күп тапкырлар соклананалар. Сержант 1944 елның февралендә яу кырында батырларча һәлак була.

Хәбибуллин Зәки Хәбибулла улы – подполковник, укчылар полкы командиры. 1911 елда Югары

в различных частях, в 1939-1940 гг. участвовал в Советско-финляндской войне.

В Отечественной войне – с первых ее дней. Окончив курсы переподготовки, стал строевым командиром. Заки Хабибуллин руководил 1069-ым полком 311-й стрелковой дивизии (61-я армия, I Белорусский фронт).

Перед Двинской стрелковой дивизией стояла задача переправиться по льду через Вислу и прорвать оборонительные рубежи гитлеровцев в районе Пулько. В свою очередь командир дивизии главную роль в предстоящем наступлении отводил полку подполковника Хабибуллина. Не только в своей дивизии, но и в армии Хабибуллина считали одним из лучших командиров полков.

Утром 14 января 1945 г. после получасовой артподготовки полк Хабибуллина, форсировав Вислу, выбил немцев из их позиций и успешно справился с поставленной задачей. Вырвавшись вперед, полк угрожал вражеским тылам и без отдыха преследовал врага. Приказы командования отмечали полк Хабибуллина за освобождение городов Сохачев и Лович, Лодзь и Аргенау, а также Александров.

В итоге этих успешных операций в районе Варшавы дивизия углубляется в тыл врага, создав ему угрозу окружения. За успешное выполнение боевых задач дивизия удостоилась Красного Знамени, а подполковник Хабибуллин – звания Героя Советского Союза. 1 мая 1945 г. герой погиб. Память об отважном воине-герое будет вечно жить в сердцах его земляков.

Башкиров Иван Сергеевич – сержант, командир пулеметного расчета. Родился в 1926 г. в с.Завод-Нырты. После окончания начальной школы работал в колхозе. В армию был призван в ноябре 1943 г., на фронте – с июня 1944 г.

Призвавшись в армию, Башкиров в запасном полку овладел искусством пулеметчика и через полгода был уже на передовой. Хорошо воевал молодой боец. В наступательных операциях под Ковелем, на берегах Западного Буга, в стремительном марше по польской земле он расчищал дорогу стрелкам и бесстрашно отражал контратаки гитлеровцев. В приказах командира полка не раз отмечалось имя пулеметчика Башкирова. Медаль «За отвагу», орден Красной Звезды и звание сержанта были наградой за его храбрость и находчивость.

5 февраля 1945 г. у города-крепости Дойчкроне подразделение Башкирова добивало окруженный немецкий гарнизон. Устроившись с пулеметом в разрушенном доме, Башкиров через пролом в стене косит гитлеровцев, пытавшихся прорваться

Утар авылында туа. 1931 елда армия сафларына алына, 1935 елда хәрби-сәяси училище һәм 1940 елда сәяси состав курсларын тәмамлый. Төрле частьларда комсомол һәм сәяси-техник хезмәттә була. 1939-1940 елларда Совет-фин сугышында катнаша.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтта. Яңадан хәзерлек курсларын тәмамлап, строевой командир дәрәҗәсенә ирешә. Зәки Хәбибуллин 311 укчылар дивизиясенең 1069 укчылар полкы (61 армия, I Белоруссия фронты) белән җитәкчелек итә.

Двина укчылар дивизиясе алдында боз өстеннән Висла елгасы аркылы чыгу һәм Пулько районында гитлерчылар оборонасын өзү бурычы тора. Дивизия командиры, үз чиратында, булачак һөҗүмдәге төп рольне подполковник Хәбибуллин полкына тапшыра. Үз дивизиясендә генә түгел, бөтен армиядә Хәбибуллинны иң яхшы полк командиры дип санийлар.

1945 елның 14 гыйнвары иртәсендә, ярты сәгатьлек артиллерия хәзерлеге узганнан соң, Хәбибуллинның полкы Висланы кичеп чыгып, немецларны алган позицияләреннән куып чыгаруга ирешә. Полк, алга бәреп чыгып, дошманны эзәрлекләп бара. Хәбибуллин җитәкләгән полк Сохачев һәм Лович, Лодзь һәм Аргенау, Александров шәһәрләрен алганы өчен командование приказларында билгеләп үтелә.

Варшава районындагы уңышлы операцияләр нәтиҗәсендә дивизия дошман тылына үтеп керә һәм аңа камалышта калу куркынычы белән яный. Сугышчан бурычны уңышлы үтәгәне өчен, дивизиягә Кызыл Байрак тапшырыла, ә подполковник Зәки Хәбибуллинга 1945 елның 27 февралендә Советлар Союзы Герое исеме бирелә. 1945 елның 1 маенда ул батырларча һәлак була. Каһарман сугышчының якты истәлеге якташлары күңелендә мәңге сакланыр.

Башкиров Иван Сергеевич – сержант, пулемет расчеты командиры. 1926 елда Завод-Нырты авылында туа. Башлангыч мәктәпне тәмамлап, колхозда эшли. Армия сафларына 1943 елның ноябрендә алына, 1944 елның июненнән фронтта.

Башкиров иң элек запас полкта пулеметчы осталыгын үзләштерә, ярты елдан фронтның алгы линиясендә була. Яшь солдат яхшы сугыша. Ковель янындагы, Көнбатыш Буг ярларындагы һөҗүм операцияләрендә, Польша җирләрен фашистлардан азат иткәндә ул укчыларга юл чистартып бара һәм гитлерчыларның контрһөҗүмнәрен кире кайтара. Пулеметчы Башкиров исеме командование приказларында билгеләп үтелә, батырлыгы һәм тап-

через кольцо окружения. У пулеметчика кончаются патроны. Поняв это, немцы начинают обходить дом, пытаясь взять в плен Башкирова. Взяв гранату, отважный пулеметчик бросается на врагов, погибая вместе с ними.

Звание Героя Советского Союза присвоено нашему земляку посмертно 27 февраля 1945 г. Награжден также орденами Ленина, Славы III степени и медалями.

Полный кавалер орденов Славы, уроженец с.Кильдебяк Тимергалиев Курбангали Тимергалиевич родился в 1924 г. В 1942 г. он был направлен в Чувашию, где в полковой школе получил первую солдатскую закалку, стал сержантом, учил молодых солдат искусству пулеметчика. К зиме 1943 г. попал на фронт.

Вместе с передовыми частями армии, одним из первых Тимергалиев вступил на правый берег Днепра. Его подразделению удалось захватить плацдарм и удержать его. За проявленный героизм и отвагу Курбан Тимергалиев был удостоен ордена Славы III степени.

Летом 1944 г. шли упорные бои за овладение городом Люблин. За подвиг в этих боях сержант был награжден орденом Славы II степени.

И снова бои. В одном из них в конце апреля 1945 г. при форсировании реки Нейсе и прорыве обороны в районе Будерозе вновь отличился наш земляк.

За подвиг, проявленный в бою в районе Будерозе, Курбангали Тимергалиевич Тимергалиев был отмечен орденом Славы I степени, став к своим 20-ти годам полным кавалером ордена Славы.

Закончилась война. Бывший разведчик 504-го отдельного пулеметно-артиллерийского батальона Курбангали Тимергалиев вернулся на родину – в с.Кильдебяк, затем переехал в г.Альметьевск.

Тыл в годы войны – это подлинный трудовой фронт, на котором сражались буквально все – от мала до велика. Тыловой труд – будничный, изматывающий, бесконечный – требовал подчас не меньшего мужества и упорства, не меньшего величия души, чем в окопах лицом к лицу с противником. Как и весь советский народ, сабинцы трудились, чтобы приблизить Победу.

В годы Великой Отечественной войны труженики колхоза «Кзыл-Куряш» внесли большой вклад в обеспечение фронта хлебом. В 1941 г. хозяйство было поделено на два колхоза, председателем был избран Назиб Сафиуллин. А в 1944 г. были образованы еще два колхоза – «Гимн» и «Фронтовик». Несмотря на то, что число колхозов в селе уве-

кырлыгы өчен ул «Батырлык өчен» медаленә һәм Кызыл Йолдыз орденына лаек була, аңа сержант дәрәҗәсе бирелә.

1945 елның 5 февралендә Дойчкроне шәһәрныгытмасы өчен барган сугышларда Башкиров подразделениесе камалышта калган немец гарнизонын юк итә. Үзенең пулеметы белән бер җимерек йортка урнашып алып, чолганышны өзәргә омтылган гитлерчыларга бер-бер артлы ата башлый. Пулеметчының патроннары бетә. Моны аңлап алган немецлар йортны уратып алалар, Башкировны әсирлеккә алырга телиләр. Ул, кулына граната алып, дошман өстенә ташлана, үзе дә шунда һәлак була.

Якташыбызга Советлар Союзы Герое исеме үлеменнән соң, 1945 елның 27 февралендә бирелә. Ул шулай ук Ленин, III дәрәҗә Дан орденнары, медальләр белән бүләкләнгән.

Дан орденының тулы кавалеры, Килдебәк авылы тумасы Тимергалиев Корбангали Тимергали улы 1924 елда туа. 1942 елда Чуашстанда полк мәктәбендә беренче хәрби чыныгу ала, сержант дәрәҗәсенә күтәрелеп, яшь солдатларны пулеметчы һөнәренә өйрәтә. 1943 елның кышында фронтка эләгә.

Армиянең алгы частьлары белән бергә, беренчеләрдән булып, Тимергалиев подразделениесе Днепрның уң ярына кичеп чыга һәм плацдарм яулап алуга, аны ныгытуга ирешә. Бу сугышта күрсәткән батырлыгы һәм кыюлыгы өчен якташыбыз III дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнә.

1944 елның җәендә Люблин шәһәре өчен каты сугышлар бара. Монда ул батырлыгы өчен II дәрәҗә Дан орденына лаек була.

Һәм тагын сугышлар. 1945 елның апрель ахырында, Нейсе елгасын кичеп Будерозе районында дошман оборонасын өзгәндә, якташыбыз үзен кыю сугышчы итеп күрсәтә. Аны I дәрәҗә Дан ордены белән бүләклиләр. Ул чакта аңа бары 20 яшь кенә була әле.

Сугыш тәмамлана. 504 аерым пулемет-артиллерия батальоны разведчигы Корбангали Тимергалиев туган җиренә – Килдебәк авылына кайта, соңрак Әлмәт шәһәрендә яши.

Сугыш елларында тыл чын хезмәт фронтына әйләнә, монда һәркем, олысыннан кечесенә кадәр, уртак Җиңү өчен көрәшә. Тыл хезмәте – көндәлек хезмәт, талчыктыра торган, мәңге бетмәс – күп вакыт, окопларда дошман белән йөзгә-йөз очрашканнан да батыррак һәм тырышрак, рухың ныграк булуны таләп итә. Бөтен совет халкы кебек үк, сабалылар да Җиңүне якынайтып хезмәт куя.

Бөек Ватан сугышы елларында «Кызыл көрәш» колхозы хезмәтчәннәре фронтны икмәк белән тәэмин итүгә зур өлеш кертәләр. 1941 елда бу

личилось, людские ресурсы уменьшились. Если в 1940 г. в колхозе было 1409 колхозников, в 1941 г. их осталось всего 859. На развитие оборонной промышленности на Урал и в Сибирь из колхоза «Кзыл-Куряш» выехали 382 человека.

Таким образом, тяжелый труд в тылу выпал на долю стариков, женщин и подростков. Из-за недостатка рабочих лошадей в полевых работах использовались волы и коровы. Вновь начали сеять лукошками.

Активно помогали колхозу учащиеся Сабинской школы. В районной газете «Колхоз байрагы» от 7 ноября 1941 г. было сообщение о том, что на уборке урожая 1941 г. приняли участие 116 учеников, они выработали 4860 трудодней.

О самоотверженном труде женщин в годы войны можно было бы рассказать многое. Они с честью выполнили выпавшую на их долю огромную задачу. Возьмем колхоз «Гимн». В 1945 г. из 212 колхозников 144, из 22 трактористов 15 были женщинами. Работать на сложных молотилках приходилось подросткам и женщинам. Одновременно работали по 40 человек. Рабочих рук остро не хватало.

Сабинский район шефствовал над Казанским госпиталем. Только в феврале 1943 г. жители с.Богатые Сабы отправили для раненых 1,5 центнера мяса, 50 штук зубного порошка, 15 подушек.

В годы войны среди колхозников распространяли облигации военных займов. В 1941 г. в Фонд обороны наш район внес 56 718 рублей, а за годы войны – 1 514 980 рублей.

Как было отмечено на страницах газеты «Колхоз байрагы» от 9 мая 1946 г., за годы войны от населения Сабинского района на фронт было отправлено 772 шубы, 510 телогреек, 481 пара брюк, 1262 рубашки, 3248 пар варежек и носков, 1155 шапок, 1735 пар валенок; сдано для фронта 396 888 пудов картофеля, 54 618 пудов овощей, 86 502 пуда мяса, 3 308 994 литра молока, 2 243 230 штук яиц, 106 212 пудов брынзы, 353 514 пудов шерсти, 33 066 штук кожи. Такая сердечная забота о защитниках страны вдохновляла на быстрейший разгром врага.

В годы войны мастера-меховщики поселка Шемордан радовали солдат, офицеров и гражданское население своими теплыми шапками-ушанками, варежками, полушубками, унтами.

Несмотря на то, что большинство мужчин было мобилизовано на фронт, колхозникам приходилось выезжать на оборонительные работы. В кильдебякских, шепшенарских лесах шла заготовка дре-

хуҗалык икегә бүленә, рәис итеп Нәҗип Сафиуллин сайлана. Ә 1944 елда тагын ике хуҗалык – «Гимн» һәм «Фронтовик» колхозлары оеша. Авылда колхозлар саны артса да, эшче көчләр саны кими. 1940 елда колхозда 1409 эшче булса, 1941 елда аларның саны 859 га кала. Оборона сәнәгатен үстерү өчен Урал һәм Себер якларына «Кызыл көрәш» колхозыннан 382 кеше китә.

Шул рәвешле, тылдагы авыр хезмәт картлар, хатын-кызлар һәм яшүсмерләр җилкәсенә төшә. Атлар җитмәү сәбәпле, кыр эшләренә үгезләр һәм сыерлар җигелә, чәчү чәчәргә тубаллар асып чыгарга туры килә.

Саба мәктәбе укучылары колхозларга зур ярдәм күрсәтәләр. «Колхоз байрагы» район газетының 1941 елның 7 ноябрь санында 116 укучының урыпҗыюда катнашканлыгы, аларның барлыгы 4860 хезмәт көне эшләгәнлекләре турында мәкалә басыла.

Сугыш елларында хатын-кызларның фидакарь хезмәте турында да бик күп язарга булыр иде. Алар үзләренә йөкләнгән эшне намус белән башкаралар. Мәсәлән, «Гимн» колхозында 1945 елда 212 колхозчының 144е, 22 тракторчының 15е хатын-кызлар булган. Катлаулы ашлык сугу җайланмаларында да хатын-кызлар һәм яшүсмерләр эшли.

Саба районы Казан госпитален шефлыкка ала. 1943 елның февраль аенда гына да Байлар Сабасы авылы халкы яралылар өчен 1,5 центнер ит, 50 данә теш порошогы, 15 мендәр җибәрә.

Сугыш елларында колхозчылар арасында хәрби займ облигацияләре тараталар. 1941 елда Оборона фондына безнең район 56 718 сум, сугыш елларында барысы 1 514 980 сум акча күчергән.

«Колхоз байрагы» газетының 1946 елның 9 май санында күрсәтелгәнчә, Саба районы халкы фронтка 772 тун, 510 бишмәт, 481 чалбар, 1262 ирләр күлмәге, 3248 пар бияләй һәм оекбаш, 1155 баш киеме, 1735 пар киез итек җыйнап җибәрә; сугыш елларында фронт өчен 396 888 пот бәрәңге, 54 618 пот яшелчә, 86 502 пот ит, 3 308 994 литр сөт, 2 243 230 данә йомырка, 106 212 пот брынза, 353 514 пот йон, 33 066 данә тире тапшырыла. Якташларының мондый кайгыртучанлыгы Ватан сагына басучыларны яңадан яңа җиңүләргә рухландыра.

Сугыш елларында Шәмәрдән поселогының тире эшкәртү осталары солдат-офицерларны һәм тылдагы халыкны үзләренең колакчынлы бүрекләре, бияләйләре, кыска туннары һәм мех итекләре белән куандыралар.

Күпчелек ир-атларның фронтка китүенә карамастан, колхозчылар окоп казу, урман кисү эшләренә

весины, через станцию Иштуган она отправлялась на фронт. Лесозаготовщикам не хватало одежды, основной пищей были вареный без соли горох и чечевичный калач.

Много было забот на селе: вести животноводство, обеспечить земледелие семенами. Все необходимое приходилось возить на лошадях из Казани. Обычно из колхоза в Казань везли древесную кору, а привозили соль. Местом для ночлега в пути был кукчинский лес. «Когда навстречу ехала машина, голову лошади накрывали шалью и придерживали поводья, чтобы не пугалась», – вспоминали потом участники тех походов.

Война отняла у многих родных и близких, но никто не в силах отнять нашу память. Сейчас наш долг – назвать и сохранить для потомства имена наших земляков, сражавшихся на полях Великой Отечественной и в тылу: и тех, кто сложил на полях сражений свои головы, и тех, кому посчастливилось вернуться в наш родной район победителями, и тех, кто своим доблестным трудом приближал Победу в тылу.

**РАИС МИННИХАНОВ,**
*глава Сабинского муниципального района*

дә йөриләр. Килдебәк, Шепшеңәр урманнарында агач әзерләү эше бара, ул Иштуган станциясе аша фронтка озатыла.

Авылда мәшәкатьләр санап бетергесез күп: терлекчелекне алып барырга, чәчүлек орлык әзерлисе бар. Кирәкле әйберләрне атлар белән Казаннан ташыйлар. Гадәттә колхоздан Казанга агач кайрысы алып баралар, аны тозга алыштырып кайталар. Юлда кунып калу урыны булып Кукчә урманы санала. «Каршыга машина килсә, атның башына шәл ябып, курыкмасын өчен тотып тора идек», –дип искә ала ул юлларны күп таптаган авыл халкы.

Сугыш бик күпләрнең туганнарын, якын кешеләрен тартып ала, әмма йөрәкләрдә уелган исемнәрне, хатирәләрне беркем тартып ала алмый. Безнең төп бурычыбыз – Бөек Ватан сугышы фронтларында кулына корал тотып көрәшкән һәм тылда фидакарь хезмәт куйган һәркемне: яу кырында батырларча һәлак булганнарны, җиңүчеләр булып районыбызга әйләнеп кайтканнарны, тылда фидакарь хезмәт куйганнарны исемләп атау һәм киләчәк буыннарга амәнәт итеп тапшыру.

**РӘИС МИҢНЕХАНОВ,**
*Саба муниципаль районы башлыгы*

# С П И С О К

## уроженцев и жителей
## Сабинского района,
## мобилизованных Сабинским РВК,
## сражавшихся на фронтах
## Второй мировой войны
## и вернувшихся с Победой




## Саба районында туган, яшәгән,
## Саба РХК тарафыннан
## мобилизацияләнгән,
## Икенче бөтендөнья сугышы
## фронтларын кичеп, илгә
## Җиңү алып кайтучылар

# И С Е М Л Е Г Е

**АБДРАХМАНОВ (АБДУРАХМАНОВ) Мансур Абдрахманович,** 1920 г.р., место рожд.: с.Кильдебяк, место жит.: п.Лесхоз. Моб. в 1940 г., гв. ст-на, санинструктор, 28 гв. ап, 9 гв. сд, демоб. в 1944 г. Место раб.: Сабинский лесхоз, гл. бухгалтер. Кавалер орденов Славы III ст., Отечественной войны I ст.

**АБДРАХМАНОВ (ГАБДРАХМАНОВ) Ислам (Исламгалей) Джиганшинович,** 1906 (1909) г.р., место рожд.: с.Мичанбаш. Моб. в 1941 г. Сабинским РВК, ряд., 974 сп; 791 ап, 254 сд.

**АБДРАХМАНОВ Фатхри (Фатхрахман) Абдрахманович,** 1919 г.р., место рожд.: с.Кильдебяк. Моб. в 1940 г., ряд., демоб. в 1946 г. Место раб.: военно-учетный стол, нач. Кавалер ордена Отечественной войны II ст. Умер в 1989 г.

**АБДУЛЛИН Бикбай Миннебаевич,** 1910 г.р., место рожд.: с.Старая Икшурма. Моб. в 1941 г., ряд., демоб. в 1945 г. Место раб.: к-з «Красный пахарь», колхозник. Умер в 1952 г.

**АБДУЛЛИН Валимухамет Абдуллович,** 1897 г.р., место рожд.: с.Мичанбаш. Моб. в 1943 г., ряд. Место раб.: п.Шемордан, повар. Умер в 1984 г.

**АБДУЛЛИН Габдельфарт Зарифович,** 1926 г.р., место рожд.: с.Богатые Сабы. Моб. в 1944 г., ряд., демоб. в 1950 г. Место раб.: райпо, шофер.

**АБДУЛЛИН Гайнулла Габдулович,** 1904 г.р., место рожд.: Арский р-н, с.Хасаншаих. Моб. в 1942 г. Балтасинским РВК, гв. ряд., повозочный батареи, 73 гв. сп, 25 гв. сд; с-т. Место раб.: Балтасинский райпотребсоюз, пред.; мехкомбинат, директор. Кавалер ордена Отечественной войны I ст. Заслуженный работник торговли ТАССР. Умер в 1987 г.

**АБДУЛЛИН Гали Абдуллович,** 1921 г.р., место рожд.: д.Куюк. Моб. в 1941 г., ряд., демоб. в 1944 г. Место раб.: к-з «Юлбашчы», колхозник. Умер в 1994 г., похоронен в г.Уфа Башкортостана.

**ГАБДРАХМАНОВ Мансур Габдрахман улы,** 1920 елда Килдебәк ав. туган, яшәү урыны: Лесхоз п. 1940 елда моб., гв. ст-насы, санитария инструкторы, 1944 елда демоб. Эш урыны: Саба урман хуҗалыгы, баш бухгалтер. III дәрәҗә Дан, I дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры.

**ГАБДРАХМАНОВ Исламгали Җиһанша улы,** 1906 (1909) елда Мичәнбаш ав. туган. 1941 елда Саба РХК моб., ряд.

**ГАБДРАХМАНОВ Фәтхрахман Габдрахман улы,** 1919 елда Килдебәк ав. туган. 1940 елда моб., ряд., 1946 елда демоб. Эш урыны: хәрби исәпкә алу өстәле, начальник. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 1989 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Бикбай Миңнебай улы,** 1910 елда Иске Икшермә ав. туган. 1941 елда моб., ряд., 1945 елда демоб. Эш урыны: «Красный пахарь» к-зы, колхозчы. 1952 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Вәлимөхәммәт Абдулла улы,** 1897 елда Мичәнбаш ав. туган. 1943 елда моб., ряд. Эш урыны: Шәмәрдән п., пешекче. 1984 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Габделфәрт Зариф улы,** 1926 елда Байлар Сабасы ав. туган. 1944 елда моб., ряд., 1950 елда демоб. Эш урыны: р-н кулланучылар җәмгыяте, машина йөртүче.

**АБДУЛЛИН Гайнулла Габдулла улы,** 1904 елда Арча р-ны, Хәсәншәех ав. туган. 1942 елда Балтач РХК моб., гв. ряд., батареядә олаучы; с-т. Эш урыны: Балтач р-ны кулланучылар берлеге, рәис; мех комбинаты, директор. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. ТАССРның атказанган сәүдә хезмәткәре. 1987 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Гали Абдулла улы,** 1921 елда Көек ав. туган. 1941 елда моб., ряд., 1944 елда демоб. Эш урыны: «Юлбашчы» к-зы, колхозчы. 1994 елда вафат булган, Башкортстанның Уфа ш. җирләнгән.

**АБДУЛЛИН Галимулла Абдуллович,** 1921 г.р., место рожд.: с.Юлбат, место жит.: с.Татарская Икшурма. Моб. в 1941 г., ст. с-т, демоб. в 1945 г. Место раб.: к-з «Татарская Икшурма», пред. Кавалер ордена Красной Звезды. Умер в 1953 г., похоронен в г.Ангарск Иркутской обл.

**АБДУЛЛИН Гинният (Гениад) Абдуллович,** 1919 г.р., место рожд.: с.Юлбат. Моб. в 1942 г. Сабинским РВК, гв. ряд., телефонист, 207 гв. гап, 5 гв. габр, 2 гв. ад прорыва РГК, ЮФ, III БФ, демоб. в 1945 г. Место раб.: к-з «Искра», зав. фермой. Кавалер ордена Отечественной войны I ст. Умер в 1994 г.

**АБДУЛЛИН Ибрай,** 1911 г.р. Моб. в 1941 г. Сабинским РВК, ряд., тракторист, 189 тяж. габр, 29 ад прорыва РГК, ВолхФ, ЛенФ, I БФ, демоб. в 1945 г. Кавалер ордена Красной Звезды.

**АБДУЛЛИН Карим Абдуллович,** 1913 г.р., место рожд.: с.Кильдебяк. Моб. в 1944 г., ряд., демоб. в 1945 г. Место раб.: к-з «Октябрь», разнорабочий. Умер в 1981 г.

**АБДУЛЛИН Каримулла Абдуллович,** 1922 г.р., место рожд.: с.Юлбат. Моб. в 1941 г., ряд., демоб. в 1944 г. Кавалер ордена Отечественной войны II ст.

**АБДУЛЛИН Леонтий Степанович,** 1910 г.р. Моб. в 1941 г., с-т, 255 ап, демоб. в 1946 г. Место раб.: молкомбинат, мастер.

**АБДУЛЛИН Мансур Ибрагимович,** 1925 г.р., место рожд.: с.Мартыново. Моб. в 1943 г. Владивостокским ГВК Приморского кр., л-т, ком. взвода, 360 сп, 74 сд, 104 ск, 57 А, III УФ. Кавалер орденов Красной Звезды, Отечественной войны II ст.

**АБДУЛЛИН Махмут (Махмет) Абдуллович,** 1924 г.р., место рожд.: с.Богатые Сабы. Моб. в 1942 г., ст. матрос, комендор-наводчик, 14 отд. ад-н, БФл, демоб. в 1947 г. Место раб.: управление связи, монтер. Умер в 1976 г.

**АБДУЛЛИН Мубаракзян (Мубарак) Абдуллович,** 1925 г.р., место рожд.: с.Тюбяк. Моб. в 1943 г., ряд., 214 сп, ДВФ, демоб. в 1948 г. Место раб.: с-з «Икшурминский», механизатор. Кавалер ордена Отечественной войны II ст.

**АБДУЛЛИН Галимулла Абдулла улы,** 1921 елда Юлбат ав. туган, яшәү урыны: Татар Икшермәсе ав. 1941 елда моб., өлкән с-т, 1945 елда демоб. Эш урыны: «Татар Икшермәсе» к-зы, рәис. Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. 1953 елда вафат булган, Иркутск өлк. Ангарск ш. җирләнгән.

**АБДУЛЛИН Гыйният Абдулла улы,** 1919 елда Юлбат ав. туган. 1942 елда Саба РХК моб., гв. ряд., телефончы, 1945 елда демоб. Эш урыны: «Искра» к-зы, ферма мөдире. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 1994 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Ибрай,** 1911 елда туган. 1941 елда Саба РХК моб., ряд., тракторчы, 1945 елда демоб. Кызыл Йолдыз ордены кавалеры.

**АБДУЛЛИН Кәрим Абдулла улы,** 1913 елда Килдебәк ав. туган. 1944 елда моб., ряд., 1945 елда демоб. Эш урыны: «Октябрь» к-зы, төрле эштә эшләүче. 1981 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Кәримулла Абдулла улы,** 1922 елда Юлбат ав. туган. 1941 елда моб., ряд., 1944 елда демоб. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры.

**АБДУЛЛИН Леонтий Степанович,** 1910 елда туган. 1941 елда моб., с-т, 1946 елда демоб. Эш урыны: сөт комбинаты, мастер.

**АБДУЛЛИН Мансур Ибраһим улы,** 1925 елда Мәртен ав. туган. 1943 елда Приморье кр. Владивосток ШХК моб., л-т, взвод ком. Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры.

**АБДУЛЛИН Мәхмүт Абдулла улы,** 1924 елда Байлар Сабасы ав. туган. 1942 елда моб., өлкән матрос, комендор-төзәүче, 1947 елда демоб. Эш урыны: элемтә идарәсе, монтер. 1976 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Мөбарәкҗан Абдулла улы,** 1925 елда Төбәк ав. туган. 1943 елда моб., ряд., 1948 елда демоб. Эш урыны: «Икшермә» с-зы, механизатор. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры.

**АБДУЛЛИН Нигъматулла Абдуллович,** 1921 г.р., место рожд.: д.Чабки-Сабы. Моб. в 1942 г., ряд., демоб. в 1942 г. Место раб.: д.Чабки-Сабы, зав. клубом. Умер в 1976 г.

**АБДУЛЛИН Нигъмәтулла Абдулла улы,** 1921 елда Чәбки-Саба ав. туган. 1942 елда моб., ряд., 1942 елда демоб. Эш урыны: Чәбки-Саба ав., клуб мөдире. 1976 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Нурулла Абдуллович,** 1924 г.р., место рожд.: д.Чабки-Сабы. Моб. в 1942 г., ряд., демоб. в 1942 г. Умер в 1974 г.

**АБДУЛЛИН Нурулла Абдулла улы,** 1924 елда Чәбки-Саба ав. туган. 1942 елда моб., ряд., 1942 елда демоб. 1974 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Хатмулла Абдуллович,** 1909 г.р., место рожд.: с.Богатые Сабы. Моб. в 1942 г., ряд., демоб. в 1942 г. Место раб.: пожарная команда. Кавалер ордена Отечественной войны II ст. Умер в 2000 г.

**АБДУЛЛИН Хәтмулла Абдулла улы,** 1909 елда Байлар Сабасы ав. туган. 1942 елда моб., ряд., 1942 елда демоб. Эш урыны: янгын сүндерү командасы. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 2000 елда вафат булган.

**АБДУЛЛИН Хидиятулла Габдуллович,** 1892 г.р., место рожд.: д.Мамалаево. Моб. в 1942 г., ряд., демоб. в 1944 г. Разнорабочий. Умер в 1978 г.

**АБДУЛЛИН Һидиятулла Габдулла улы,** 1892 елда Мамалай ав. туган. 1942 елда моб., ряд., 1944 елда демоб. Төрле эштә эшләүче. 1978 елда вафат булган.

**АБЕЛХАЕРОВ Ахмет Абелхаерович,** 1922 г.р., место рожд.: с.Кильдебяк. Моб. в 1941 г., ряд., демоб. в 1947 г. Место раб.: к-з «Яна-Тормыш», тракторист. Умер в 1947 г.

**ӘБЕЛХӘЕРОВ Әхмәт Әбелхәер улы,** 1922 елда Килдебәк ав. туган. 1941 елда моб., ряд., 1947 елда демоб. Эш урыны: «Яңа тормыш» к-зы, тракторчы. 1947 елда вафат булган.

**АБЗАЛОВ (АВЗАЛОВ) Маргам (Маркан) Абзалович,** 1923 г.р., место рожд.: д.Суля. Моб. в 1942 г. Сабинским РВК, ефр., ст. разведчик-наблюдатель, 8 б, 105 габр, 7 ад прорыва РГК, II УФ, III УФ, демоб. в 1947 г. Место раб.: к-з «Яна-Юл», колхозник. Кавалер двух орденов Красной Звезды, ордена Отечественной войны II ст. Умер в 1995 г.

**АБЗАЛОВ Мәрһәм (Мәргән) Абзал улы,** 1923 елда Сүлә ав. туган. 1942 елда Саба РХК моб., ефр., өлкән разведчик-күзәтүче, 1947 елда демоб. Эш урыны: «Яңа юл» к-зы, колхозчы. Ике Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры. 1995 елда вафат булган.

**АБСАЛЯМОВ Касыйм Абсалямович,** 1909 г.р., место рожд.: с.Верхний Отар. Моб. в 1941 г. Сабинским РВК, гв. ряд., стрелок, 2 сд, 99 ск, 7 А, КалинФ, ЛенФ; 18 сд, 31 ск, 7 гв. ВА, КарФ, демоб. в 1945 г. Место раб.: к-з им. Калинина, колхозник. Кавалер ордена Красной Звезды. Умер в 1979 г.

**ӘБСӘЛӘМОВ Касыйм Әбсәләм улы,** 1909 елда Югары Утар ав. туган. 1941 елда Саба РХК моб., гв. ряд., укчы, 1945 елда демоб. Эш урыны: Калинин исем. к-з, колхозчы. Кызыл Йолдыз ордены кавалеры. 1979 елда вафат булган.

**АБСАЛЯМОВ Минзакир Абдурахманович,** 1896 г.р., место рожд.: с.Верхний Отар, место жит.: г.Москва. Моб. в 1919 г., ком. стрелковой бригады, 17 зсбр; 18 сд, 8 А, ЮЗФ, ВолхФ, КарФ; генерал-майор, ком. стрелкового корпуса, 131 ск, 14 А, ЛенФ, III ПриБФ, демоб. в 1967 г. Место раб.: Высшая военная академия им. К.Е. Ворошилова, ст. преподаватель. Кавалер орденов Ленина, Богдана

**ӘБСӘЛӘМОВ Миңнезакир Габдрахман улы,** 1896 елда Югары Утар ав. туган, яшәү урыны: Мәскәү ш. 1919 елда моб., укчылар бригадасы ком.; генерал-майор, укчылар корпусы ком., 1967 елда демоб. Эш урыны: К.Е. Ворошилов исем. Югары хәрби академия, өлкән укытучы. Ленин, I дәрәҗә Богдан Хмельницкий, II дәрәҗә Суворов, дүрт Кызыл Байрак, Хезмәт Кызыл Байрагы,

Хмельницкого I ст., Суворова II ст., четырех орденов Красного Знамени, орденов Трудового Красного Знамени, «Знак Почета». Умер 10.6.1981, похоронен в г.Москва.

«Почет Билгесе» орденнары кавалеры. 10.6.1981 вафат булган, Мәскәү ш. җирләнгән.

**АБУБАКИРОВ Абуталип Абубакирович,** 1914 г.р., место рожд.: п.Арск, место жит.: с.Богатые Сабы. Моб. в 1936 г., в/служащий, демоб. в 1944 г. Место раб.: райисполком, конюх. Кавалер ордена Отечественной войны II ст. Умер в 1993 г.

**ӘБҮБӘКЕРОВ Әбуталип Әбүбәкер улы,** 1914 елда Арча п. туган, яшәү урыны: Байлар Сабасы ав. 1936 елда моб., х/хезмәткәр, 1944 елда демоб. Эш урыны: р-н башкарма комитеты, ат карауچы. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 1993 елда вафат булган.

**АБУБАКИРОВ Тимергазим Абубакирович,** 1926 г.р., место рожд.: с.Тимершик. Ряд., демоб. в 1947 г. Место раб.: к-з им. Пушкина, колхозник.

**ӘБҮБӘКЕРОВ Тимергазыйм Әбүбәкер улы,** 1926 елда Тимершык ав. туган. Ряд., 1947 елда демоб. Эш урыны: Пушкин исем. к-з, колхозчы.

**АБУТАЛИПОВ Гайнутдин Абуталипович,** 1908 г.р., место рожд.: д.Сабай. Моб. в 1941 г. Сабинским РВК, ряд., стрелок, 413 сп, ЗФ, демоб. в 1943 г. Место раб.: к-з «Кзыл-Трактор», зав. фермой. Кавалер ордена Отечественной войны I ст. Умер в 1989 г.

**ӘБУТАЛИПОВ Гайнетдин Әбуталип улы,** 1908 елда Сабай ав. туган. 1941 елда Саба РХК моб., ряд., укчы, 1943 елда демоб. Эш урыны: «Кызыл трактор» к-зы, ферма мөдире. I дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 1989 елда вафат булган.

**АВЗАЛОВ (АБЗАЛОВ) Заман Авзалович,** 1914 г.р., место рожд.: Камско-Устьинский р-н, с.Атабаево, место жит.: с.Богатые Сабы. Моб. в 1936 г., ряд. Место раб.: к-з им. К.Маркса, тракторист. Кавалер ордена Отечественной войны II ст. Умер в 1989 г.

**АФЗАЛОВ Заман Афзал улы,** 1914 елда Кама Тамагы р-ны, Атабай ав. туган, яшәү урыны: Байлар Сабасы ав. 1936 елда моб., ряд. Эш урыны: К.Маркс исем. к-з, тракторчы. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 1989 елда вафат булган.

**АВХАДИЕВ Хасан Авхадиевич,** 1919 г.р., место рожд.: с.Евлаштау. Моб. в 1941 г., ряд., демоб. в 1942 г. Место раб.: к-з им. Калинина, колхозник. Умер в 1979 г.

**ӘҮХӘДИЕВ Хәсән Әүхәди улы,** 1919 елда Яулаштау ав. туган. 1941 елда моб., ряд., 1942 елда демоб. Эш урыны: Калинин исем. к-з, колхозчы. 1979 елда вафат булган.

**АГЗАМОВ Абубакир Агзамович,** 1910 г.р., место рожд.: с.Казанчи Бигеней. Моб. в 1941 г., ряд., демоб. в 1943 г. Место раб.: к-з «Марс», колхозник. Умер в 1981 г.

**ӘГЪЗАМОВ Әбүбәкер Әгъзам улы,** 1910 елда Казанчы Бигәнәй ав. туган. 1941 елда моб., ряд., 1943 елда демоб. Эш урыны: «Марс» к-зы, колхозчы. 1981 елда вафат булган.

**АГЛИЕВ (АГАЛИЕВ) Асатулла (Асад) Аглиевич (Хайруллович),** 1924 (1925) г.р., место рожд.: с.Старый Мичан. Моб. в 1944 г. Сабинским РВК, мл. с-т, стрелок, 338 сп, 96 сд, 53 ск, 48 А, БФ, демоб. в 1944 г. Место раб.: к-з им. Тукая, бригадир. Кавалер орденов Красной Звезды, Отечественной войны II ст. Умер в 1986 г.

**ӘҺЛИЕВ Әсәтулла Әһли (Хәйрулла) улы,** 1924 (1925) елда Иске Мичән ав. туган. 1944 елда Саба РХК моб., кече с-т, укчы, 1944 елда демоб. Эш урыны: Тукай исем. к-з, бригадир. Кызыл Йолдыз, II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры. 1986 елда вафат булган.

**АГЛИЕВ Мухамет Аглиевич,** 1925 г.р., место рожд.: с.Кренни. Моб. в 1943 г., ряд., демоб. в 1943 г. Место раб.: к-з им. Тукая, колхозник. Умер в 1984 г.

**ӘҺЛИЕВ Мөхәммәт Әһли улы,** 1925 елда Кернле ав. туган. 1943 елда моб., ряд., 1943 елда демоб. Эш урыны: Тукай исем. к-з, колхозчы. 1984 елда вафат булган.

**АГЛИУЛЛИН Зиятдин Аглиуллович,** 1893 г.р., место рожд.: с.Большой Арташ. Моб. в 1942 г., ряд., демоб. в 1945 г. Место раб.: с-з «Икшурминский», рабочий. Умер в 1961 г.

**ӘҺЛИУЛЛИН Зыятдин Әһлиулла улы,** 1893 елда Олы Арташ ав. туган. 1942 елда моб., ряд., 1945 елда демоб. Эш урыны: «Икшермә» с-зы, эшче. 1961 елда вафат булган.

**АГЛЯМЗЯНОВ (АГЛАМОВ) Мансур Аглямзянович,** 1923 (1925) г.р., место рожд.: д.Язлы Арташ. Моб. в 1942 г., ряд., демоб. в 1945 г. Место раб.: с-з «Икшурминский», разнорабочий. Кавалер ордена Отечественной войны II ст. Умер в 2015 г., похоронен в д.Язлы Арташ.

**ӘГЪЛӘМҖАНОВ (ӘГЪЛӘМОВ) Мансур Әгъләмҗан улы,** 1923 (1925) елда Язлы Арташ ав. туган. 1942 елда моб., ряд., 1945 елда демоб. Эш урыны: «Икшермә» с-зы, төрле эштә эшләүче. II дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры. 2015 елда вафат булган, Язлы Арташ ав. җирләнгән.

**АГЛЯМОВ Миркадам Аглямович,** 1926 г.р., место рожд.: д.Язлы Арташ. Моб. в 1944 г., ряд., демоб. в 1945 г. Место раб.: Сабабашское лесничество, лесник. Умер в 2004 г., похоронен в д.Язлы Арташ.

**ӘГЪЛӘМОВ Миркадәм Әгъләм улы,** 1926 елда Язлы Арташ ав. туган. 1944 елда моб., ряд., 1945 елда демоб. Эш урыны: Сабабаш урманчылыгы, урманчы. 2004 елда вафат булган, Язлы Арташ ав. җирләнгән.

**АДГАМОВ Габзалил Адгамович,** 1900 г.р., место рожд.: с.Казанчи Бигеней. Моб. в 1941 г., ряд., демоб. в 1945 г. Место раб.: к-з «Эшчан», колхозник. Умер в 1950 г.

**ӘДҺӘМОВ Габҗәлил Әдһәм улы,** 1900 елда Казанчы Бигәнәй ав. туган. 1941 елда моб., ряд., 1945 елда демоб. Эш урыны: «Эшчән» к-зы, колхозчы. 1950 елда вафат булган.

**АДГАМОВ Мусавир Адгамович,** 1926 г.р., место рожд.: с.Нижние Шитцы. Моб. в 1943 г., ряд., демоб. в 1950 г. Место раб.: к-з «1 Мая», шофер. Умер 20.8.1984, похоронен в с.Нижние Шитцы.

**ӘДҺӘМОВ Мөсәвир Әдһәм улы,** 1926 елда Түбән Шытсу ав. туган. 1943 елда моб., ряд., 1950 елда демоб. Эш урыны: «1 Май» к-зы, машина йөртүче. 20.8.1984 вафат булган, Түбән Шытсу ав. җирләнгән.

